КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 июнь г.Казань № 519

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 24 ноябрь, 570 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 24 ноябрь, 570 нче карарына, 3 пунктта «50,0» саннарын «65,0» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына 60 көн эчендә «Республика яшьләр, инновацион һәм профилактик программалар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе уставына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә, анда «Республика яшьләр, инновацион һәм профилактик программалар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең түбәндәге вәкаләтләрен күздә тотарга кирәк»:

үз компетенцияләре кысаларында психологик ярдәм күрсәтүнең комплекслы системасын гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары ведомство буйсынуындагы социаль өлкә оешмалары (алга таба – социаль өлкә оешмалары) эшчәнлегенә мониторинг;

социаль өлкә оешмалары белгечләре эшчәнлеген консультация һәм методик яктан тәэмин итү, шул исәптән:

үз компетенцияләре кысаларында психологик ярдәм мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар проектларын эшләү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

психологик ярдәм мәсьәләләре буенча норматив хокукый актларның мәгълүмат-белешмә базасын формалаштыруда һәм актуаль хәлдә тотуда катнашу;

психологик хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча методик һәм мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү;

социаль өлкә оешмалары эшчәнлеге практикасына эшнең нәтиҗәле формаларын һәм методларын кертү;

җәмгыятьтәге психологик киеренкелеккә анализ һәм мониторинг;

белгечләр эшчәнлеген мәгълүмат белән тәэмин итү, статистик хисаплылык системасын камилләштерү һәм үстерү, социаль өлкә оешмалары һәм үз компетенцияләре кысаларында психологик ярдәм күрсәтүче белгечләр эшчәнлеген исәпкә алу һәм камилләштерү.

3. Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына әлеге карарның 1 һәм 2 пунктларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә оештыру карарларын кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин